КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 июнь г.Казань № 681

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 декабрь, 1404 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 декабрь, 1404 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 316 номерлы карары белән расланган «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасына 41 нче кушымтада китерелгән «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты нәтиҗәләренә ирешү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет

учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатлар өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты структурасына керә торган «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» федераль проектының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыру өчен «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – учреждение) субсидия (алга таба – шул ук эзлеклелектә субсидия, төбәк проекты) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен билгели.

Субсидияне финанс белән тәэмин итү чыганагы – төбәк проекты нәтиҗәләренә ирешү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы.»;

2 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан башка бюджетара трансферт рәвешендә бирелә торган акча исәбеннән төбәк проектны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү өчен гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә расланган» сүзләрен «төбәк проектны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә субсидия (шул исәптән федераль бюджеттан Татарстан республикасы бюджетына субсидия акчасы исәбеннән) бирү өчен гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә куючы һәм учреждение субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

Килешү, шул исәптән әлеге килешүгә үзгәрешләр кертүне яки аны өзүне күздә тоткан өстәмә килешү Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып төзелә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия төбәк проектны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә субсидия (шул исәптән федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия акчасы исәбеннән) бирү өчен гамәлгә куючыга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

9 пунктта «кимендә 40» сүзләрен «кимендә 44» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин